л) мөрәҗәгать итүченең техник шартларны үтәвен мониторинглау өчен һәм тиешле календарь елы эчендә газ бүлү оешмасының газ бүлү челтәренә фактта тоташтыруны гамәлгә ашыру өчен газ бүлү оешмасының чыгымнар составы (9 нчы кушымта), стандартлаштырылган тариф ставкасын исәпләү тәртибе буенча аңлатма язуын (С7) теркәп;

м) тиешле календарь елында башкарылган килешүләр буенча технологик тоташтыру кысаларында газ бүлү һәм газ куллану объектлары төзелешенә чыгымнар турында белешмәләр (10 нчы кушымта), башкарылган эшләр актлары (КС-2, КС-3, КС-14 унификацияләнгән формалары), башкарылган эшләр актлары булмаганда – эш төрләре буенча локаль һәм җыелма смета хисаплары.

2.5.2. Җир кишәрлеге чикләре эчендә технологик тоташтыру өчен түләү билгеләү өчен газ бүлү оешмасы тапшыра торган материаллар:

а) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат һәм стандартлаштырылган тариф ставкасын исәпләү тәртибе буенча аңлатма язуы белән, газ куллану челтәрен проектлауга стандартлаштырылган тариф ставкасының исәпләмәсе (Спр);

б) коррозиядән электрохимик яклау системасы җайланмалары һәм газүткәргеч төзүгә стандартлаштырылган тариф ставкасының исәпләмәсе ($С_Г$) һәм газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат;

в) газны редукцияләү пунктын урнаштыруга стандартлаштырылган тариф ставкасы исәпләмәсе ($С_{прг}$) һәм газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат;

г) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат һәм сүндергеч җайланмалар урнаштыруга стандартлаштырылган тариф ставкасы исәпләмәсе ($С_{оу}$);

д) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат һәм Мөрәҗәгать итүченең капиталь төзелеш объектында эчке газүткәргеч урнаштыруга стандартлаштырылган тариф ставкасы исәпләмәсе ($С^{г}_{окс}$);

е) газ бүлү оешмасының чыгымнары турында мәгълүмат һәм газны исәпкә алу приборы урнаштыруга стандартлаштырылган тариф ставкасы исәпләмәсе ($С_{пу}$).

ж) тиешле календарь елында башкарылган килешүләр буенча технологик тоташтыру кысаларында газ бүлү һәм газ куллану объектлары төзелеше буенча чыгымнар турында белешмәләр (10 нчы кушымта), башкарылган эшләр актлары (КС-2, КС-3, КС-14 унификацияләнгән формалары), башкарылган эшләр актлары булмаганда – эш төрләре буенча локаль һәм җыелма смета хисаплары.

2.5.3. Методик күрсәтмәләрнең 4 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында каралган газ кулланучы җайланмаларны технологик тоташтыруга түләүне исәпләү өчен газ бүлү оешмасы тапшыра торган материаллар:

а) чираттагы календарь елына түләү билгеләү турында гариза (2 нче кушымта).

Гариза газ бүлү оешмасының вәкаләтле заты тарафыннан имзалана һәм (булган очракта) газ бүлү оешмасының мөһере белән беркетелә.

б) агымдагы елның 1 октябренә актуаль булган, бухгалтерлык исәбенә алу максатларында газ бүлү оешмасының исәпкә алу сәясәте;

в) тоташтыру (технологик ялгау) чараларын гамәлгә ашыру өлкәсендә эшләүче газ бүлү оешмасының структур бүлекчәләре хезмәткәрләренең сан исәбе,

